Күмәкләштерү сәясәте Мәмәширгә дә килеп җитә. Колхоз оештыру өчен 1930 елда шәһәрдән егермебишмеңче коммунист Кашшаф Нуретдинов җибәрелә. Г. Сәгыйдуллин, З. Шәрипов, Г. Мөхетдинов, К. Мөхәммәтшин, С. Мөхәммәтдинов, Б. Кәримуллин, А. Шәяхмәтов, Х. Нигъмәтҗанов, Н. Хәлимов, Б. Абдуллин гариза язып колхозга керәләр.



**Колхоз идарәсе алды**

11 хуҗалыктан торган бу колхозның рәисе итеп Нуретдинов сайлана. Күмәк хуҗалык «Электро» дип атала.



1931 елда “Электро”га 78 хуҗалык берләшә, 1932 елда барлык крестьяннар да колхозга кереп бетә. 8 кырчылык, бер яшелчәчелек, бер төзү бригадасы оештырыла.

1931 елның җәендә колхозга биш «Фордзон» тракторы кайта. Беренче тракторчылар Салихҗан Сабирҗанов, Мөхәммәтдин Закиров була. Колхоз ике автомашина сатып ала, аларга Газизулла Мөхетдинов һәм Габделбәр Мөхлисуллиннар утыра.



**Колхозның каланча бинасы**

Күмәкләштерү башлангач, Тәмәй авылында да “Кустарь” колхозы оеша. Авыл 70-80 хуҗалыктан торган. Күмәк хуҗалык бай һәм алдынгылардан саналган.

Кешеләр игенчелек, терлекчелектән тыш, кустарьлык белән дә шөгыльләнә. Алар бөтен янәшә-тирәдә үзләре кайнаткан сумала, дегет, үзләре яндырган агач күмере белән дан тота.

Колхоз төзү елларында авылда өч коммунисттан партячейка, 17 кешедән комсомол ячейкасы оеша.

1934 елда ячейканың сәркятибе итеп Хәбибҗамал Сәгыйдуллина - Хисмәтова сайлана. Әгъзалар 50 кешегә җитә. Комсомоллар халык алдында әңгәмә-лекцияләр үткәрәләр, концерт- спектакльләр куялар. Мәмәшир комсомол оешмасы алдынгы булып, республика күләмендә макталып бара. Ячейка сәркятибе Сәгыйдуллина Татарстан комсомолының XV конференциясендә ВЛКСМ Өлкә комитеты пленумы члены булып сайлана.



**Х. Сәгыйдуллина**

Үзәк кибет урынында, ике катлы агач бинада балалар бакчасы һәм ясле эшләп килә. Аның аскы катында ашханәдә ризык әзерлиләр.

**Ике катлы балалар бакчасы**





Беренче авыл Советы Шәмәй күпере каршындагы каравыл өендә, аннан Закир бай йортында эшли. Рәис итеп Зариф Шәрипов сайланган.

1935 елда клуб төзелә. Бинага китапханә, кызыл почмак, чәч алу бүлмәсе урнаша. Мөдире булып Гали Хөсәенов, китапханә мөдире булып Сәйдә Мотыйгуллина эшләгән. Тау башы урамында медпункт ачыла, фельдшер Әзәл Латыйпов халыкка хезмәт күрсәтә.




**Кино будкасы алды**



Болында яшелчә үстерелгән. Яшелчәчелек бригадасын Габдулла Касыймов, Миңлебикә Заһидуллина җитәкләгән.

Әле сугыштан соңгы елларда да яшелчә бригадасы районда дан тоткан. Бакчачылык та нык үскән. Болындагы җиләк-җимеш бакчасыннан чиләк-чиләк карлыган җыеп алганнар.





**Болында коры елларда да кыяр, кәбестә, шалкан, гәрәнкә, помидор, аш чөгендере уңган**

Күрсәткеч тактада 8 бригаданың да эш нәтиҗәләре язып барылган. Җиңүчеләр самолет, уртада баручылар ат, артта калганнар ташбака белән билгеләнгән.





Алдынгыларны кызыл тактага, артта калучыларны кара тактага язганнар. «Электро» колхозы районда алдынгылар рәтендә йөргән.





Мәмәширнең итекчеләр авылы дигән даны еракларга таралган. Шуны исәпкә алып булса кирәк, авылда 1930 елда итек басу артеле оештырыла. Аны «Промартель» дип тә йөрткәннәр. Промартельдә итекне түшәү, басу, шомарту-агарту, киптерү цехлары була. Шунда ук йон саклау һәм әзер итекләрне кабул итү складлары, башка ярдәмче биналар, канцелярия... Артель үзе китапханә ачкан.

Промартельне оештырганда ике максат күздә тотылган. Авыл халкы кыш айларында эш белән тәэмин ителгән, монда 70-75 кеше эшләгән. Ул елларда техника, фермаларда мал-туар аз булу сәбәпле, эш барлык кешегә дә җитмәгән. Икенчедән — илдә киез итеккә ихтыяҗ нык арткан. Алар армия кирәкләренә, урманчыларга, төзүчеләргә һәм экспортка киткән. Итекләр чиста йоннан, озын кунычлы итеп басылган. Эшләү гел кулдан булган. Итекләрне милли орнаментлар белән бизәгәннәр. Артель белән Каюмов Ваһап җитәкчелек иткән.

Бөек Ватан сугышыннан соң промартель Кукмарадагы “Ил” фабрикасы карамагына күчә. Барлык корылмалар сүтеп алына. Бары “Әртил тавы” гына кала.









Сугыштан соң «Электро» колхозы әкренләп күтәрелә.

Илленче елларда «Кустарь» колхозы «Электро»га кушыла.


Колхоз әкренләп ныгый, сыер, дуңгыз, сарык, тавык фермалары төзелә. 1957 елда колхозда 140 баш ат, 216 баш эре терлек, 270 баш дуңгыз, 406 баш сарык, 500 дән артык тавык, үрдәк исәпләнә. Йөк машиналары саны алтыга җитә. Бригадалар эреләндерелә.

50-60 елларда авылны электрлаштыру һәм радиолаштыру төгәлләнә.

1960 елда «Электро»ны «Революция» колхозына кушалар. Алты авыллы яңа колхоз «Татарстан» исемен ала. Мәмәширдә комплекслы бригада оештырыла.

1979 елның июлендә Мәмәшир «Үрнәк» колхозы булып аерылып чыга. Авылда яңа Авыл советы оеша.

Трассага тоташтырып юл күтәртелә, җәелә. Елга аша тимер-бетон күпер салына башлый. Машина-трактор паркы үсеп чыга.



**Күмәк хуҗалык җирләре картасы**

Тәмәйдә сарык фермасы оештырыла, аны алга чыгару өчен мөдире Фәйзелгаян Фәттахов зур көч куя.

80 елларда Мәмәширдә ике катлы балалар бакчасы, элемтә бүлекчәсе, китапханә файдалануга бирелә. 1990 елларда авылда пекарня төзелә, теш дәвалау кабинеты ачыла. Автомат-телефон станциясе төзелә.

«Үрнәк» колхозы күмәк авыл хуҗалыгы предприятиесе итеп үзгәртелә, аннан “Бөр” агрофирмасына берләшә. “Вамин”да да булып ала. Авылда фермер хуҗалыклар да оеша.



**Мәмәшир һәм Тәмәй пекарнялары**



Туган туфракка төпләнеп, ата-бабалары җирендә тамыр җибәреп, хезмәттән тәм, тормыштан ямь табып гомер кичергән шәхесләребез күп безнең.

Планнан тыш ашлык саткан өчен «Электро» Кукмара районында беренче булып йөк автомашинасы белән бүләкләнә. Вакыйф Зыятдинов ГАЗ—51 автомашинасын Казанга барып алып кайта. 1954 елда аны Горький авто- заводыннан яңа автомашина алып кайтырга җибәрәләр. Вакыйф тәҗрибәле шоферлардан санала, хөкүмәт бүләкләренә лаек була, 41 ел рульне кулдан төшерми. Аңа «Үрнәк» колхозының атказанган колхозчысы» исеме бирелә.



**Вакыйф Зыятдинов**

Тракторчылар Расим Мөхлисуллин, Хәсән Габделхаков, Нурулла Зәкиуллин, Рәшит Хисамиев, Илдар Гайфетдинов, Мидхәт Фәттахов, Нәҗих Гәрәев, Наил Ганиев, шоферлар Хәмзә Галимуллин, Рәфкать Кадыйров, Илдар Шәрипов, Фоат Ваһапов, Вакыйф Шакиров, Әскәр Сабирҗанов, төзүчеләр Вакыйф Җиһангәрәев, Рәшит Сафиуллин, терлекчеләр Наилә Хәлиуллина, Миңлебәдәр Рамазанова, Зөлкамал Хәсәнҗанова, Әлфинур Газизова, Саимә Шәрипова һ.б. — авыл үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр.

Газ хуҗалыгы кураторы булган Вагыйз Ваһапов авыл йортларын «зәңгәр ягулык» белән тәэмин итү өчен зур көч куя, «Почет билгесе» ордены һәм өч медаль белән бүләкләнә. Мөдәррис Идрисов трактор йөртә, озак еллар бригада белән җитәкчелек итә, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.



**Мөдәррис Идрисов**



**Вагыйз Ваһапов**

Комбайнчы Габделхәй Кадыйров, терлекче Нажия Галимуллина, ветврач Зиннәтулла Зәкиуллин, баш бухгалтер Нурзидә Шәрифуллина, журналист Нурулла Шәрифуллин һ.б. үз тармаклары буенча республиканың атказанган хезмәткәре исемен йөртә.



**Алдынгылар слетында. 1992 ел.**